СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

19.01.2021 ел № 6-33

с. Шеланга

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шиланга авыл җирлеге Советы карары проекты турында

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44нче статьясына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставына таянып,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советының Карар проектын хупларга, аны беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, эшне дәвам итәргә (1нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча киләсе составтагы тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров;

эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре Н. В – Антонова;

Эшче төркем әгъзалары:

– Соляр Василий Мариянович - 3 нче номерлы Шилангы сайлау округы депутаты.

- Емельянова Вера Анатольевна-2 нче номерлы Шилангы сайлау округы депутаты.

3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советының карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2нче кушымта).

4. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советының карар проекты хакында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3нче кушымта).

5. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча халык алдында тыңлауларны 2021нче елның 2нче февралендә 10.00 сәгатьтә Шилангы авылы, Октябрь урамы, 53нче йорт адресы буенча Шилангы мәдәният йортында уздырырга.

6. Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советының
2021нче елның 19нчы гыйнварыннан
6-33нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Уставның 6нчы статьясындагы 1нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 16нчы пунктча өстәргә:

«18) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү»;

2. Уставның 16нчы статьясындагы 9нчы пунктына түбәндәге эчтәлекле 7нче пунктча өстәргә:

«7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау турындагы мәсьәлә буенча карар кабул итү»;

3. Уставның 19нчы статьясындагы 6нчы пунктына түбәндәге эчтәлекле 5нче пунктча өстәргә:

«5) авыл торак пунктында яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган мәсьәләләр буенча инициативалы проект кертү турында инициатива белән чыгыш ясарга хокуклы»;

4. Уставның 21нче статьясындагы 1нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу, халыкка җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау, территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен җирлек территориясендә гражданнар җыелышлары үткәрелергә мөмкин. Гражданнар җыелышлары микроҗирлекләр, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортлар буенча чакырыла»;

5. Уставның 23нче статьясындагы 3нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 3нче пунктча өстәргә:

«3) унтугыз яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган җирлек халкы яисә аның бер өлеше - әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен»;

6. Уставның 23нче статьясындагы 5нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 6нчы пунктча өстәргә:

«6) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе»;

7. Уставның 23нче статьясындагы 7нче пунктының 1нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) җирле бюджет акчалары исәбеннән-җирле үзидарә органнары яисә җирлек халкы инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә»;

8. Уставның 85нче статьясындагы 3нче пункты үз көчен югалткан дип танырга;

9. Уставның 94нче статьясындагы 2нче пунктының 2нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлек башлыгы муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставы турындагы белешмәләрне муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан "Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында" 2005нче елның 21нче июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4нче статьясындагы 6нчы өлешендә каралган Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә кергән көннән алып җиде көн эчендә җирлек уставын, җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш».

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советының
2021нче елның 19нчы гыйнварыннан
6-33нче карарына
2 нче кушымта

ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘРҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА КАРАТА ГРАЖДАННАР ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ.

1. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Карары проектына тәкъдимнәр 2021нче елның февраленә кадәр, авторның яшәү урыны турында белешмәләрне күрсәтеп, язма рәвештә кертелә. Тәкъдимнәр мәгълүмат стендларында игълан ителгән көннән башлап, көн саен 8.00 дән 16.00 гә кадәр шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советында эшче төркем секретаре Антонова Н. В. 422577, Шилангы авылы, Октябрьская урамы, 53 йорт адресы буенча кабул ителә. Белешмәләр өчен телефон: (884-379) 2-04-79

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советының
2021нче елның 19нчы гыйнварыннан
6-33нче номерлы карарына
3нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАРЫ ПРОЕКТЫ ХАКЫНДА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАР КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

1. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 422577, Шилангы авылы, Октябрь урамы, 53нче йорт адресы буенча, Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетына Н.В.Антоновага шәхсән яки почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» дигән тамга белән) кабул ителә.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Советына язма гаризалар биргән халык тыңлауларында үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән җирлек халкы катнаша.

3. Халык тыңлауларында халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган халкы катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланырга 30 минут кала башлана.

5. Ачык тыңлауларда катнашучылар, чыгыш ясау хокукы белән, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументлау өчен чакырыла.

6. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

7. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

8. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны бүлдерергә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

9. Катнашучылар тарафыннан ачык тыңлауларны уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В. Майоров